КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 декабрь г.Казань № 968

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен, «Түбән Кама технология көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен һәм «Түбән Кама нефть химиясе көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру турында» 2017 ел, 17 февраль, 89 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен, «Түбән Кама технология көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен һәм «Түбән Кама нефть химиясе көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру турында» 2017 ел, 17 февраль, 89 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2017 елның 1 сентябреннән Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумында - 1385 кеше, Түбән Кама нефть химиясе көллиятендә - 1019 кеше һәм Түбән Кама технология көллиятендә – 363 кеше укучыларны әти-әниләре (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә, Түбән Кама технология көллиятендә укучы 168 кешене, шул исәптән «Пешекче, кондитер» һөнәре буенча – 49 кеше, «Тегүче» – 36 кеше, түбәндәге

белгечлеләр буенча укучы: «Җәмәгать туклануы продукциясе технологиясе» (йөреп уку бүлеге) – 63 кешене, «Җәмәгать туклануы продукциясе технологиясе» (читтән торып уку бүлеге) – 11 кешене, «Коммерция (тармаклар буенча)» – 9 кешене Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумында, Түбән Кама технология һәм Түбән Кама нефть химиясе көллиятләрендә гамәлдә булган укыту шартларын һәм программаларын саклап,«Түбән Кама күппрофильле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә күчерергә;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне кертергә:

Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумының, Түбән Кама нефть химиясе көллиятенең һәм Түбән Кама технология көллиятенең Түбән Кама шәһәре, Студенческая урамы, 29 нчы йорт һәм Түбән Кама шәһәре, Химиклар проспекты, 33 нче йорт адреслары буенча урнашкан оператив идарә хокукында Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә бирелергә тиешле мөлкәте исемлеген;

Түбән Кама технология көллиятенең оператив идарә хокукында «Түбән Кама күппрофильле көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә (алга таба – Түбән Кама күппрофильле көллияте) бирелергә тиешле мөлкәте исемлеген;

Түбән Кама шәһәре, Химиклар проспекты, 33 нче йорт адресы буенча урнашкан Түбән Кама технология көллиятенең Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы милкенә бирелергә тиешле мөлкәте исемлеген;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Түбән Кама күппрофильле көллияте өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсенә тиешле үзгәрешләр кертергә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карарга кул куйган көннән:

30 көн эчендә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тапшырган мөлкәт исемлеге нигезендә оператив идарә хокукында Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумыныкы, Түбән Кама нефть химиясе көллиятенеке һәм Түбән Кама технология көллиятенеке булган Түбән Кама шәһәре, Студенческая урамы, 29 нчы йорт һәм Түбән Кама шәһәре, Химиклар проспекты, 33 нче йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә оператив идарә хокукында бирергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тапшырган мөлкәт исемлеге нигезендә оператив идарә хокукында Түбән Кама технология көллиятенеке булган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Түбән Кама күппрофильле көллиятенә оператив идарә хокукында бирергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тапшырган мөлкәт исемлеге нигезендә оператив идарә хокукында Түбән Кама технология көллиятенеке булган, Түбән Кама шәһәре, Химиклар проспекты, 33 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкенә бирергә;

120 көн эчендә Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына керетргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин